ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АЛЕКСЕЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АЛЕКСЕЕВСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

27.12.2024 п.г.т.Алексеевское № 611

**Алексеевск муниципаль районы Башкарма комитетының 12.08.2019 ел, №339 «Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Башкарма комитетындагы шәхси мәгълүматлар турында» карарына үзгәрешләр кертү хакында**

«Шәхси белешмәләр турында» Федераль законга, Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү һәм «Банклар һәм банк эшчәнлеге турында» Федераль законның 30 статьясындагы ундүртенче өлешенең үз көчен югалтуын тану хакында» 2022 елның 14 июлендәге 266-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә

**карар бирәм:**

1. Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Башкарма комитетының 12.08.2019 ел, № 339 карары белән расланган Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Башкарма комитетында шәхси белешмәләр субъектларының яисә аларның вәкилләренең соратуларын карау Кагыйдәләренә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

- 3 пунктка түбәндәге эчтәлекле 9_1 пунктчасы өстәргә: «9_1) «Шәхси мәгълүматлар турында»2006 елның 27 июлендәге 152-ФЗ номерлы Федераль законның 18_1 статьясында билгеләнгән бурычларны операторның үтәү ысуллары хакындагы мәгълүматны.

2. Әлеге карарны Алексеевск муниципаль районының рәсми сайтында, Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында, шулай ук Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының Алексеевск район Советы бинасындагы мәгълүмат стендында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз артымда калдырам.

**Башкарма комитет җитәкчесе** **О.Н. Леденцов**